**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы «Кече Чынлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кече Чынлы торак пунктында гражданнар җыены**

**КАРАРЫ**

2020 нче елның 2 нче декабре Кече Чынлы авылы № 1

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы «Кече Чынлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кече Чынлы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2020 елның 2 декабре Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Кече Чынлы авыл җирлеге Уставының 12.1 статьясы нигезендә Кече Чынлы авыл җирлеге Советының 2019 елның 7 октябрендәге 53/1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Кече Чынлы авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмә, әлеге хисап комиссиясе нигезендә 2020 нче елның 2 нче декабрендә тавыш бирү нәтиҗәләре турында, аның нигезендә:

Халык җыенында катнашучылар исемлегенә тавыш бирү тәмамланган вакытта җыенда катнашучылар исемлегенә 1086 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны - 786, бу исә торак пункт территориясендә гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә кертелгән гражданнарның 72,38 % ын тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

“за” позициясе өчен халык җыенында катнашучы 786 кеше тавыш бирде, Бу тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучыларның 100% ын тәшкил итә; «каршы» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде, бу 0% тәшкил итә.

Бәян ителгәннәр нигезендә хәл иттеләр:

1.2020 нче елның 2 нче декабрендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы «Кече Чынлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кече Чынлы торак пунктында гражданнар җыенын 2020 нче елның 2 нче декабрендә уздырылган дип таныргa, гражданнар җыены нәтиҗәләре-дөрес.

2.Түбәндәге мәсьәлә буенча карар кабул итәргә: "2021 нче елда Чүпрәле муниципаль районының Кече Чынлы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә җибәрүгә килешәсезме?:

- Карл Маркс, Ленин урамнарындагы юлларга вак таш салу;
-Казан урам юлын ремонтлау;
-Карл Маркс урамындагы куперне ремонтлау».

3.2020 нче елда Чүпрәле муниципаль районы Кече Чынлы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчасын кертергә һәм алынган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Карл Маркс, Ленин урамнарындагы юлларга вак таш салу;
-Казан урам юлын ремонтлау;
-Карл Маркс урамындагы куперне ремонтлау.

4.Халык җыены нәтиҗәләрен «Туган як» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Кече Чынлы авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Кече Чынлы
авыл җирлеге башлыгы,
халык җыенында
рәислек итүче: Г.Ш.Халитов